ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.03.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 781**

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыруга территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2 2019 елның 31 октябрендәге 988 номерлы карары нигезендә , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә субсидияләр бирү тәртибен расларга (1 нче кушымта) .

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2014 елның 25 декабрендәге 2721 номерлы;
- «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2015 елның 01 апрелендәге 685 номерлы.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2024 елның 01 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (htpp:/pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның24 мартындагы
781 номерлы карарына
кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә субсидияләр бирү кагыйдәләрен билгели.

2. Әлеге Тәртип территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыруга территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 31 октябрендәге 988 номерлы карарын үтәү йөзеннән эшләнгән.

3. Субсидияләр законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә куелган Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә (алга таба - ТИҮ, субсидия алучылар) бирелә.

4. Субсидияләр әлеге Тәртипнең 1 п.1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә бирелә.

5. Субсидияләр Зеленодольск муниципаль районы Советының Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - район Башкарма комитеты) тарафыннан субсидия бирү турындагы шартнамә нигезендә бирелә.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе субсидия алу өчен район Башкарма комитетына ирекле формада субсидия бирүне сорап турында гариза тапшыра (җибәрә).

Гаризада түбәндәгеләр күрсәтелә:

**а) юридик затлар өчен:**

- Территориаль иҗтимагый үзидарә исеме, ФИО Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе, субсидия алучының банк реквизитлары, Территориаль иҗтимагый үзидарәнең юридик һәм фактик адреслары турында белешмәләр, контакт телефоннары.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

- Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе раслаган Уставның күчермәсе;
- субсидия бирү турында гариза тапшыру көненә кадәр кимендә бер ай кала Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә;
- Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен сайлау турында гражданнар җыелышы (конференциясе) беркетмәсе.

**б) физик затлар өчен:**

- ФИО, паспорт мәгълүматлары яки Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенең шәхесен раслаучы башка документ мәгълүматлары, субсидия алучының исәп-хисап счеты, яшәү (тору) урыны буенча теркәлү адресы, контакт телефоннары.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

- Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисенең паспорт яисә шәхесен раслаучы башка документ күчермәсе;

- Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисен сайлау турында гражданнар җыелышы (конференциясе) беркетмәсенең күчермәсе.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе ай саен хисап аеның соңгы числосына Район Башкарма комитетына үзе рәисе булган территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге турында әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча хисап тапшыра.

8. Районның Башкарма комитеты әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән гаризаны һәм әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән хисапны терки.

9. Хисапны теркәгән көннән алып 10 эш көне эчендә тапшырылган документларны әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрнең туры килүенә тикшерә. Субсидия алучы әлеге Тәртиптә каралган шартларга туры килгәндә, Район Башкарма комитеты субсидия бирү турында Карар кабул итә.

10. Субсидия күләме Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесенә компенсация түләвен тәэмин итү кирәклеген исәпкә алып, җитәкченең еллык акчалата түләүләреннән чыгып, ай саен бер тапкыр 15 түләү күләмендә , бер тапкыр түләү ай саен, икенче, өченче, дүртенче квартал йомгаклары буенча билгеләнә. Юридик зат булган Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесенә шәһәр (авыл) җирлеге өчен компенсация түләү күләме - аена 20 502,70 сум (иминият кертемнәрен исәпкә алып); юридик зат булмаган Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесенә шәһәр (авыл) җирлеге өчен компенсация түләү күләме - аена 15 747,10 сум (иминият кертемнәрен исәпкә алып).

11. Субсидия күчерү субсидия алучының кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына Район Башкарма комитеты тарафыннан ай саен хисаптан соң килә торган айның 10 числосына кадәр башкарыла.

12. Субсидия алучы әлеге Тәртиптә күрсәтелгән шартларга туры килмәсә, Район Башкарма комитеты баш тарту турында карар кабул итә һәм әлеге карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә субсидия алучыга баш тарту турында нигезләрен күрсәтеп хәбәр җибәрә.

13. Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе тапшырылган документларның һәм аларда булган белешмәләрнең дөреслеге өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нормалары нигезендә җаваплы.

14. Район Башкарма комитеты муниципаль финанс контроле органнары белән берлектә субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерә.

15. Субсидия алучы тарафыннан субсидияне бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылганда, шулай ук субсидиядән максатчан файдаланмау факты, Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе тапшырган документларның һәм алардагы белешмәләрнең дөрес булмавы ачыкланган очракта, бирелгән субсидияләр субсидия алучы тарафыннан кире кайтару турында язма таләп алынган көннән алып җиде эш көне эчендә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итүгә субсидияләр бирү турындагы Тәртипкә кушымта

_______________________________________________

(территориаль иҗтимагый үзидарә исеме)

ХИСАП

20____елның ________________ өчен

| РФ, ТР законнарында билгеләнгән территориаль иҗтимагый үзидарәләр вәкаләтләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек | Дата | Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген финанслау чаралары (чыганаклары) | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| | | | |

Кушымта:
- фотохисаплар;
-счетлар һ. б.

Имза
Дата